РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Түйкә,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 ноябрь 2023ел

№5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Туйкә авылының Совет ур. 1 йорттан 41 йортка кадәр, Крайняя ур. 1 йорттан 8 йортка кадәр, Яшьләр ур. 1 йорттан 20 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен, 2023 елның 02 декабрендә 09 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Туйкә авылының Гагарин ур. 1 йорттан 18 йортка кадәр, Җәлил ур. 1 йорттан 17 йортка кадәр, Киров ур. 1 йорттан 28 йортка кадәр, Ленин ур. 1 йортткан 21 йортк акадәр, Үзәк ур. 1 йорттан 7 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен, 2023 елның 02 декабрендә 10 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Туйкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 2023 елның 02 декабрендә 09.00 сәг.тән 10.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 2023 елның 02 декабрендә 10. 00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Туйкә авылы, Гагарин ур., 4А йорт, Туйкә авылы мәдәният йорты залы;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2023 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түйкә авылы, Җәлил урамы,19 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Түйкә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Түйкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, гаилә әгъзалары мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гаиләләр, ирекле хезмәткәрләр, контракт буенча хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә махсус хәрби операциядә катнашучылар дан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түйкә авылын урам яктырту җайланмасы (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар, урам яктыртуны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр сатып алу һәм алыштыру);
- Түйкә торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту(Түйкә авылына юлларны кардан чистарту, Киров урамында вак ташлар сатып алу, ташу, салу (килешү буенча эш өчен түләү, тракторчыга хезмәт хакы түләү));
- традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (куакларны кисү, экскаватор белән төпләрне кысу, гербицид алу, тулаем гербицид белән химик эшкәртү, үләнне кисү, килешү буенча эш өчен түләү)
- Түйкә авылында халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгару (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, коеларны ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, материаллар ,җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алмаштыру, килешү буенча эш өчен түләү) оештыру;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү - «Сабантуй " майданы (сәхнә, беседка, гирлянд, капка сатып алу; баганалар сатып алу һәм урнаштыру,); балалар мәйданчыгы (тирбәлеш, тау, карусель,) һәм янәшәдәге халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (чүп үләннәрен чистарту һәм чүп үләннәрен кисү)

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, һәм түбәндәге адреслар җуенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы-Күл, Ленин ур., тукталыш янында;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында;

7. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Рәис Р.Р.Закирова